# Туган көн – күңелле бәйрәм



# *Туган көн - күңелле бәйрәм.*

Тиздән дустым Сашаның туган көне. Аңа 12 яшь була. Мине дустым туган көнгә чакырды. Мин аны туган көне белән котладым. Кунаклар дустыма күп бүләкләр бирделәр. Ул аларга бик шатланды һәм рәхмәт әйтте. Аннары Саша кунакларны бәйрәм табынына чакырды. Балалар бергәләп тәмле ризыклар белән чәй эчтеләр.

# Сүзлек эше

| | |
|---|---|
| бәйрәм | праздник |
| күңелле | веселый |
| кунаклар | гости |
| котлады | поздравил |
| бүләкләр | подарки |
| Табын | накрытый стол |
| ризык | еда,пища |

## Сораулар:

- Туган көн – нинди бәйрәм?
- Тиздән кемнең туган көне булачак?
- Аңа ничә яшь була?
- Дустыма нәрсәләр бирделәр?
- Саша шатландымы?
- Саша кунакларны нәрсәләр белән сыйлады?

# Диалогны укыгыз.

-Сәлам, Света!

-Исәнме, Ира!

- Света, иртәгә минем туган көнем, мин сине туган көнгә чакырам.

- Рәхмәт, Ира. Сәгать ничәдә?

- Көндезге икедә.

- Яхшы, мин килермен.

## Киңәш бирегез:

дуслар Сашага нәрсә бүләк итәргә мөмкин?

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| К | И | Т | К | Д | А | Р |
| Ч | Ә | А | А | И | К | А |
| Ә | К | П | Л | С | К | Н |
| Ч | Р | Ә | Ә | М | А | Д |
| Б | У | С | Е | М | Ш | У |
| У | Я | К | Ы | Ч | Н | Е |

# Киңәш бирегез:

дуслар Сашага нәрсә бүләк итәргә мөмкин?

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| К | И | Т | К | Д | А | Р |
| Ч | Ә | А | А | И | К | А |
| Ә | К | П | Л | С | К | Н |
| Ч | Р | Ә | Ә | М | А | Д |
| Б | У | С | Е | М | Ш | У |
| У | Я | К | Ы | Ч | Н | Е |

# Табын янына чакыру, кыстау формалары

***- Табынга рәхим ит!***

***- Әйдә, өстәл янына рәхим ит!***

***- Я инде, тагын бер чынаяк чәй эч!***

***-Бәлешне ашагыз әле!***

***- Чәкчәк белән сыйланыгыз!***

***- Өчпочмактан авыз итегез!***

***- Ашыгыз тәмле булсын!***

# Татар халык ашлары









# КУНАК БУЛСАҢ , ТЫЙНАК БУЛ! МӘКАЛЬ



# Табын янында үзеңне ничек тотарга кирәк соң?

Табын янында

- акыллы, тәртипле балалар кунакта үз- үзләрен матур тота;

-кычкырып сөйләшмиләр;

- «зинһар», «рөхсәт итегез» сүзләрен кулланалар;

- авызны чапылдатырга ярамый;

- тиз ашарга ярамый;

- алдан ашый башларга ярамый;

- ризыкны сайлап алырга ярамый.

## Нокталар урынына тиешле сүзләр куеп укы.

**Туган көн - .......... бәйрәм. Тиздән дустым Сашаның ..........көне. Аңа 12 ....... була. Мине дустым туган ....... чакырды. Мин аны туган көне белән............. Дустыма күп ........... бирделәр. Ул аларга бик ........... һәм рәхмәт ........... . Аннары Саша ......... бәйрәм табынына чакырды. Балалар бергәләп тәмле ризыклар белән ...... эчтеләр.**